ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.11 2020 ел Болгар ш. № 637

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының "2020-2025 елларга Спас муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" муниципаль программасын раслау турында 16.06.2020, №335 карары белән расланган "2020-2025 елларга Спас муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (№ 535, 25.09.2020 ел үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләренә 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 27 октябрендәге 1747 номерлы РФ Хөкүмәте Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының "2020-2025 елларга Спас муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" муниципаль программасын раслау турында 16.06.2020, №335 карары белән расланган "2020-2025 елларга Спас муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" муниципаль программасына (№ 535, 25.09.2020 ел үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Программага 1 нче кушымтаның 15 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« а) әлеге Кагыйдәләргә кушымта нигезендәге рәвеш буенча гариза (Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының башкарма комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә) 2 нөсхәдә (бер нөсхә мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документларны күрсәтеп кайта);».

1.2. 18 пунктта «язмача» сүзеннән соң «яисә электрон рәвештә Бердәм портал ярдәмендә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В. Савиновка йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин